ҮЗЕБЕЗДӘ ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН

Рөстәм Миңнеханов укытучыларга Татарстанда ясалган ноутбуклар тапшырды

> 2

ЯЗГЫ ЧӘЧҮ

Кыр эшләрен акчасыз башкарып чыгып булмый

> 2

ҖИҺАНГИРЛАР

Космонавтика көнен бәйрәм итә башлавыбызга – 60 ел

> 4

ТИНЧУРИНДА – ПРЕМЬЕРА

Үлчәүнең бер тәлинкәсендә – намус, иман, икенчесендә – гөнаһ, җәза

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 51 (28824) | Сишәмбе | 12 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Актуаль мәсьәлә

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЯЗГЫ ТАШУ:
СУ ТАВЫШЫ ГЫНА ТҮГЕЛ

Соңгы көннәрдәге җылылык үзенекен итте. Республиканың берничә төбәгеннән күперләрне, урамнарны су басу, елгаларның ярларыннан ташуы турында хәбәрләр килеп ирешә. Быелгы кар күләме белән бу хәл гаҗәп түгел үзе. Су басу куркынычы булган пунктлар исемлеге төзелде, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан идарәсе белгечләре дә ташуга әзер булуларын алдан белдерде.

Шимбә киңәшмәсендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов район башлыкларына язгы ташуга бәйле вазгыятьне контрольдә тотарга кушты.

– Язгы чор башлану белән территорияләрне су басу буенча мөрәҗәгатьләр саны арта, – диде ул. – Социаль челтәрләрдә фото һәм видеолар бик күп. Шәһәр яны бистәләрен, подъездлар, ишегалларын, юлларны су басу очраклары бар. Шулай ук тротуарлар һәм җир асты кичүләренә дә су кергән. Күп кенә елгаларда су арту нәтиҗәсендә боз күтәрелде һәм хәрәкәт башланды. Түбән булган автомобиль күперләрен су басуның өч очрагы мәгълүм.

Президент җитәкчеләрне язгы ташу хакындагы хәбәр булуга, тизрәк эшкә керешергә кирәклеге хакында кисәтте. Кешеләрнең иминлеген кайгыртырга, халыкка аңлату эшләрен көчәйтергә, эш өчен кирәкле бөтен кирәк-ярак белән тәэмин итәргә кушты.

Питрәч районының Көек авылына үзебез барып күреп кайттык. Дүшәмбе иртән биредә урнашкан «Алгоритм» лицеена бару өчен көймә кирәк булган, атлап йөрерлек түгел. Дөрес, көймәләрне биегрәк машиналар алыштырган. Кайбер кешеләр балаларын укырга «Светлый» бистәсе аша озаткан. Без килгәндә дә, бер ир-ат кешеләрне кар суларыннан җыелган «күл»дән чыгарып йөри иде.

– Әйдә, сезне дә чыгарып куям, – диде ул. Акча эшләвеме дисәм, юк, савап җыюы икән. Иртәдән бирле кешеләрне үз машинасында мәктәп ягына чыгарып куя.

– Узган ел да бу юлны су баскан иде. Шөкер, йортларга керми ул. Без югарыда утырабыз, су үзәнлектә. Кар суы гына түгел ул, биредә сазлык бар. Анда гел су җыела, – ди бистәдә яшәүче Гөлнара Шәфигуллина. – Без бу хакта җитәкчеләргә дә әйттек. Юлны сала башлаганчы, төзүчеләрне җир астыннан су юллары кирәклеге турында кисәттек. Белеп торып, юл салдылар. Хәзер инде ел саен шушы хәл булачак.

Күрше урамда яшәүче Кашаповлар, бер ел элек Әлмәттәге өйләрен сатып, бу бистәгә күченгән. «Күршеләрдән сорашып торабыз. Безне су басмый, диләр. Балаларга якын булыйк дип күченгән идек. Су гына керә күрмәсен инде», – ди алар.

Мәктәпкә илтүче юл аша без дә чыгып карамакчы булдык. Машина юлына керерлек түгел. Әмма йортлар тирәсеннән такта салынган сукмак бар. Тик аннан да үтеп булмый. Үтәр өчен коймага тотынырга кирәк. Әмма анысы да кыска буйлылар өчен түгел. Биредәге тыз-быз килгән машиналарны күзәтеп торганда да, аякка су керде. Пычрак су белән коендырып китүчесе дә булды. Җиңел машиналары белән су эчендә утырып калучылар да бар. Яңа Салмачы авылында яшәүче Илмир Сабиров кире борылып китте. Икенче сменада укучы кызы Ләйсәнне башка юлдан озатырга ашыкты.

– Бистәгә күчкәндә барысын да уйлап бетермәгәнбез. Иртәнге биштән бөкеләр башлана. Мин беренче сменага улымны илттем инде. Хәзер кызымны озатам. Аннары улымны каршы алам. Кичке якта кызымны. Шушы су аркасында эшкә дә бара алмадым, – ди ул.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы Татарстан буенча идарәсенең матбугат хезмәте җитәкчесе Андрей Родыгин хәбәр иткәнчә, Бәрле елгасы күтәрелү аркасында, Кайбыч районының Борындык авылында ике урам, 30дан артык бакчага су кергән. Көек авылындагы хәлләрдән алар да хәбәрдар. Шулай ук Лаеш районының Зимняя Вишня бистәсендә дә урамнарны су баса.

– Бу бистәләрдә халык өчен куркыныч юк. Шулай ук Теләче районының Екатериновка авылында да, Мишә елгасы күтәрелеп, юлны су баскан. Әлегә авылга башка юлдан йөрергә туры киләчәк, – ди Андрей Родыгин. – Су басуга бәйле вазгыятьне коткаручылар контрольдә тота. Әгәр кеше тормышына куркыныч яный икән, ярдәм күрсәтергә әзербез. Әлегә бер авылга илтүче юл да ябылмады, кешеләрне башка урынга күчерү таләп ителми. Вазгыятьне районнарда башкарма комитет җитәкчеләре дә үз контролендә тота. Районнардагы коткаручылар да, коммуналь хезмәт күрсәтүчеләр дә су басуга әзер тора.

– Быел су кермәс төсле иде, – ди Кайбыч районының Борындык авылында яшәүче Роза Саттарова. – Кар күп булса да, басмас дип уйладык. Җирдә туң булганга су сеңә алмыйдыр инде. Ике көн су белән көрәштек. Баз да тулды, лапаслар, мунчаларга да керде. Бүген инде әкренләп чыгып бара.

Казанның Иске Победилово бистәсендәге күл ташып аккан. Анда яшәүчеләр юл аркылы да чыга алмый.

– Бистәгә кергәндә зур күлләребез бар. Быел кар күп булгач, алар ташыды. Йортларга су кермәде, – ди бистәдә яшәүче Гөлназ Гыйләҗева.

КФУның Экология һәм табигатьтән файдалану институты профессоры Юрий Переведенцев, Россия гидрометеорология үзәге мәгълүматларына да таянып, пәнҗешәмбегә кадәр көннәр җылы торачак, дип белдерде.

– Бездә шушы көннәрдә һава температурасы 4 градус җылы булырга тиеш. Әмма аномаль җылылык күзәтелә. Бездә хәзер төннәрен – 5 градус, көндез 15 градуска кадәр җылы күзәтелә. Шунлыктан кар тиз эреп, су күтәрелүләр дәвам итәчәк әле. Пәнҗешәмбедән көндезге һава температурасы 7 градус кына булачак, – диде ул. – Яңгырлар явуның да файдасы булды. Алар карны киметте. Шулай ук кояш та әкренләп карны киметә. Куркыныч су басулар булмас, дип уйлыйм.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

САН

Россия төбәкләрендә 615 йорт тирәсе мәйданына, 74 тәбәнәк күпер, 11 машина юлына су басу куркынычы яный. Кемерово өлкәсендә – 392, Смоленскида 179 йорт тирәсен су баскан.

Бәйрәм көннәре билгеле

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов 2022 елда Ураза гаете һәм Корбан гаете көннәрен рәсми билгели торган указны имзалады.

Документ буенча, быел Ураза бәйрәме 2 майда билгеләп үтеләчәк. Корбан гаете 9 июльдә була.

Ветераннарга – бүләк

Җиңүнең 77 еллыгы уңаеннан, Бөек Ватан сугышы инвалидларына һәм сугышта катнашучыларга бер тапкыр унар мең сум күләмендә акча бирелә. Россия Пенсия фондының Татарстандагы бүлеге аны түли башлаган да инде.

2019 елдан бирле Җиңү көненә бирелә торган 10 мең сум апрель аенда ук пенсия һәм башка түләүләр белән бергә киләчәк. Пенсия фонды бүлеге идарәчесе Эдуард Вафин әйтүенчә, республикада 438 ветеран Җиңү көненә шушы акчалата бүләкне алырга тиеш. Аның өчен бернинди дә гариза тапшырырга кирәкми. Түләү Пенсия фонды бүлегенең җирле органнары карамагындагы мәгълүматлар нигезендә хәл ителә.

Исегезгә төшерәбез: сугыш инвалидларына һәм ветераннарга акчалата бүләк Россия Президентының «Җиңү көненә кайбер категориядәге кешеләргә еллык акчалата түләү турында» 24 апрель, 2019 ел, № 186 карары нигезендә бирелә.

Алу гына җиңел

Татарстан вакытында түләнелмәгән кредитлар өлеше иң аз булган төбәкләр арасына кергән. Республика – 12 нче урында. 1 март мәгълүматларына караганда, бездә мондый кредитлар 3,04 процентны (12 айда 0,5 процентка кимегән) тәшкил итә. Бу хакта «РИА Новости» яза. Эшләүче бер хезмәткәрнең банкка гомуми бурычы – уртача 352 мең сум.

Вакытында түләнмәгән кредитларның азлыгы буенча Севастополь (1,87%) беренче урынны алган. Ненец автономияле округы (1,98%) – икенче, Ямал-Ненец автономияле округы – өченче (2,08%). Тулаем алганда, Россия буенча түләү вакыты чыккан кредитлар өлеше 3,85% тәшкил иткән.

Сүз уңаеннан, Татарстанда 1 гыйнварга халыкка бирелгән ипотеканың гомуми күләме 347,6 млрд сум тәшкил иткән. Бу – узган ел башындагыга караганда 28,3 процентка күбрәк.

23 күпер төзекләндерелә

Татарстанда «Сыйфатлы имин юллар» илкүләм проекты буенча 23 күпер төзекләндерелә башлаячак. 19ы инде быел ук файдалануга тапшырылырга тиеш. Юл-транспорт хуҗалыгы министрлыгыннан хәбәр ителгәнчә, күперләрнең тимер-бетон һәм корычтан эшләнгән өлешләре алыштырылачак, тирәкләре ныгытылып, яңа асфальт-бетон түшәмәләре пәйда булачак. Быел ремонт эшләренә 1,8 миллиард сум күздә тотылган. Барлыгы 20 муниципаль берәмлектә күперләр тәртипкә китереләчәк. Аерым алганда, Питрәч районында Чыты авылы янында Питрәч – Чыты – Янсуар автомобиль юлындагы үзәнлек аша салынган күпер, Чүпрәле районында Кече Чынлы елгасы күпере төзекләндереләчәк. Аксубай районында Чистай – Аксубай – Нурлат – Иске Мукшы автомобиль юлындагы Олы Сөлчә елгасы аша төзелгән күпер, шулай ук Тукай районында Князево – Казиле – Иске Абдул – Торнаташ юлында инеш күпере яңартылачак.

Финанс дәресе

Бурыч чабудан тартса

Россиядә банкротлыкка чыгучылар саны арткан. Быел беренче өч айда гына да илдә 54 меңнән артык кеше банкрот дип танылган. Бу, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 33,6 процентка күбрәк.

Шул рәвешле белгечләрнең бу уңайдан фаразлары чынга ашты. Билгеле булганча, алар, килеп туган вазгыять аркасында илдә банкротлыкка чыгучылар саны артачак, дип кисәткән иде. Шуны истә тотып, Россия Хөкүмәте 1 апрельдән кредиторлар гаризасы буенча банкротлык турында җинаять эше кузгатуга мораторий кертте.

Ул ярты ел гамәлдә булачак. Бу чара кредит буенча бурычлары булган кешегә алты ай дәвамында проблеманы хәл итәргә, яңа керем чыганаклары табарга мөмкинлек бирәчәк. Хәтерләсәгез, банкротлыкка мораторий 2020 елда – пандемия чорында да кертелгән иде. Әмма ул чакта пандемия аркасында аеруча зыян күргән тармакларга карата гына кулланылды. Быелгы мораторий исә юридик кына түгел, физик затларга, шәхси эшмәкәрләргә дә кагылачак.

Юрист Роман Архипов сүзләренә караганда, мораторий гамәлдә булган чорда кредиторлар бурычлы затны банкрот дип таный алмый. Ләкин бурычлылар өчен бу хокук элеккечә үк саклана. «Бәхеткә, банкротлык турындагы 127 номерлы федераль канун әле дә гамәлдә. Юкса, эшсезлек арту сәбәпле, күпләр айлык керемсез калырга мөмкин. Кредитны вакытында түләмәгән өчен ниләр көткәнне барыбыз да яхшы белә. Шуна күрә бу законны гамәлдән чыгарырга ярамый», – ди ул.

Роман Архипов сүзләренә караганда, үз-үзеңне банкрот дип игълан итүнең ике юлы бар. Аның беренчесе судсыз гына, икенчесе суд аша башкарыла. Бу ипотека кредитына да, кулланучыныкына да бер үк дәрәҗәдә кагыла. Судсыз юл акчалата бурыч күләме, кимендә 50 мең сум һәм күп дигәндә 500 мең сум тәшкил иткән кешеләргә туры килә. «Бу – бик тиз, җиңел һәм иң мөһиме: бушлай эшләнә торган ысул. Әмма үзеңне әлеге ысул ярдәмендә банкрот дип игълан итүнең берничә шарты бар, – ди юрист. – Моның өчен кешенең айлык түләүләр буенча бурычлары җыелган булу гына җитми. Кредит бирүченең бу кешене судка биреп, суд приставларының аның бөтен милкен, исәп-хисап счетларын тикшереп тә берни тапмаган булуы кирәк. Шушы процедураларны үткәннән соң гына кеше, үзен судсыз гына банкрот итеп тануларын сорап, Күпфункцияле үзәк аша гариза яза ала».

Суд аша үзеңне банкрот дип таныту мөмкинлегеннән кредит буенча бурыч күләме 500 мең сумнан артып, аны ким дигәндә өч ай дәвамында түләмәгән кеше файдалана ала. Бу очракта эшне Арбитраж суды тарафыннан билгеләнгән финанс идарәчесе алып барачак. «Үзен банкрот дип танытырга теләгән кеше шунысын да белеп торырга тиеш. Закон буенча, бердәнбер торактан, торак урнашкан җир участогыннан, йорт кирәк-яракларыннан башка (кыйммәтле һәм зиннәтле әйберләрдән, киемнән, яшәү минимумыннан ким булмаган акчадан тыш) барлык мөлкәт сатуга куела. Бурычлы кешенең милкен сату сатулашу (торг) аша башкарыла. Банкрот дип игълан ителгәннән соң, кеше алдагы биш ел дәвамында идарәгә бәйле вазыйфаларны башкара алмаячак. Шушы биш ел эчендә кабаттан банкларга мөрәҗәгать итәргә туры килсә, кеше кайсы елда банкротлыкка чыгуы турында аларга белгертергә тиеш. Бу факт аның кредит тарихына тискәре йогынты ясаячак, билгеле. Димәк, яңа кредит алганда да проблемалар килеп чыгарга мөмкин дигән сүз», – дип кисәтә юрист.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Сүзгә-сүз

«Татар-информ»

Марат САДЫЙКОВ, Татарстанның сәламәтлек саклау министры:

Ике ел дәвамында эш киеренке шартларда бара. Табиб яки башка медицина хезмәткәре мөмкин булганның барысын да эшли, ә пациенты җан бирә икән, бу аның психикасына зур йогынты ясый. Дөресен әйткәндә, стресс болай озакка сузылыр дип уйламаган идек, хәтта күз алдына да китерә алмадык.

(«Татар-информ»га әңгәмәсеннән)

ТАТАРСТАНДА – «СОЗВЕЗДИЕ-ЙОЛДЫЗЛЫК» ФЕСТИВАЛЕ

Быел 22 нче мәртәбә уздырылучы «Созвездие-Йолдызлык» республика фестивале ахырына якынлаша.

10 зона этабы

22 меңнән артык катнашучы

7 номинация

5 көн суперфинал (Казан, 9–13 апрель)

2 көн Гала-концерт (Казан, 14, 22 апрель)

Сөенечле хәбәр!

14 апрельгә кадәр «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына ташламалы бәядән языльп була!

П2435 җомга саны — Ташламалы бәя **423 сум 48 тиен**, гадәти бәясе – ~~488 сум 10 тиен~~

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга — Ташламалы бәя **942 сум 18 тиен**, гадәти бәясе – ~~1099 сум 32 тиен~~

Реклама 16+

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

БЕР КАЗАНДА – ИКЕ ТӘКӘ БАШЫ

Дөньякүләм вакыйгалар бүген Россия – Украина конфликтына бәйле рәвештә үсә. Сәяси вакыйгалар Европада бөтереләме, Азиядә бөреләнәме – барысына да Россиянең көнбатышында барган вакыйгаларның күләгәсе төшә. Моңарчы тын гына нейтралитет саклап яткан Швеция һәм Финляндия йөзләрен НАТОга таба бордылар. Мәскәүнең, өстәл төеп, аларга Төньяк Атлантик блокка кушылуны тыюы кире нәтиҗәгә китерде. Җитмәсә, моңарчы йөз процент диярлек Себер газын ягып яткан Финляндия аннан бик тиз баш тартачагын игълан итте. Мәскәү белән дустанә мөнәсәбәтләрдә булган Италия газны Алжирдан китертергә җыена.

Якшәмбе көнне Франциядә президент сайлавының беренче туры булып үтте. Французлар беренче турда үзләренә лидер сайлый алмадылар. Гамәлдәге президент Макрон 28,5 процент тавыш җыйды, француз уң милләтчеләре лидеры Марин Ле Пен 24,2 процент тавыш белән аның итәгенә тагылды. Ле Пен – Мәскәү тарафдары – җиңә калса, Россиягә каршы санкцияләрне алырга вәгъдә итә иде. Аның әтисе – ике меңенче елларда хакимлеккә ыргылган Жан-Мари Ле Пен – Россиягә симпатияләре белән танылган радикал уң сәясәтче иде. Кызы шуның эзеннән бара. Франциядә аларның партиясен фашистик партия дип бәялиләр, икенче турда аңа каршы көчле блок оешып килә. 20 процентлап тавыш җыйган өченче кандидат – үтә сул партия лидеры Меланшон үз сайлаучыларын Ле Пенга тавыш бирмәскә чакырды. Димәк, Макронның янә дилбегәне тотып калуы көтелә.

Вакыйгаларның иң кайнары, сәяси детектив дәрәҗәсендәгесе Пакьстанда кайнады һәм кайнавын дәвам иттерә. Атом-төш державасы булган, яңа гына ерак арага оча торган Shaheen III «җир – җир» баллистик ракеталарын сынаган Азия дәүләтендә көтмәгәндә кискен сәяси кризис туды. Махсус хәрби операция башланыр алдыннан гына Мәскәүгә килеп, Путин белән очрашкан премьер-министр Имран Хан парламентта тавыш бирү юлы белән хакимияттән читләштерелде. Пакьстан Россия газын алырга җыена иде, Кремльдә алар «Пакьстан агымы» төзү турында килештеләр. Аңлашыла инде: Вашингтонга бу ошамады. Нәтиҗәсе – йомшак ысул белән ясалган дәүләт түнтәрелеше. Парламент, хөкүмәт җитәкчесе итеп, Шаһбаз Шәрифне билгеләде. Ләкин эш төгәлләнмәде. Имран Хан дилбегәне бирүдән баш тартты, парламент карарын законсыз дип белдерде, үз тарафдарларын урамнарга чакырды. Урамнар озак көттермәде: бар Пакьстанны түнтәрелгән премьер-министрны яклаучыларның протесты иңләп алды. Оппозиция Имран Ханның халыкта популярлыгы юк, аны бары тик чит илләрдә яшәүче диаспоралар гына ярата дип саный иде. Әлегә чынбарлык киресен күрсәтә. Газета хәбәрчесе Лахор һәм Карачидан халык белән кайнаган урамнарның видеосюжетларын алды. Пакьстан картасы протест митингларын күрсәткән ноктлар белән чуарланып беткән. Сәяси элиталар Имран Ханның түнтәрелешендә Америка кулы уйнавын белдерә. Бу берьюлы Кытайга һәм Россиягә каршы акт дип бәяләнә. Әлеге юллар язылганда, илнең сәясәт казанында ике тәкә башы бергә кайнап ята.

Россиядә

ДОЛЛАР САТУГА ЧЫГАМЫ?

Россиянең икътисад мәйданында санкцияләргә бәйле кызык хәлләр башланды. Әлегә тыюлар безне көчле итеп кенә калмый, баетып та ята. Илгә шактый валюта агылды. Углеводородларга, бигрәк тә газга бәяләр күтәрелү үз эшен эшләде. Россия сумы резерв валюталарына карата кискен ныгый башлады. Хәтта санкцияләргә кадәрге күрсәткечләрне узып китеп, илле-алтмыш сумга кадәр ныгырга ихтимал булган доллар перспективасы барлыкка килде. Долларның ныгуы – гади халык өчен яхшы күренеш инде ул. Валюта спекуляцияләре белән мавыкмасаң да, импортка бәяләр төшеп, матди хәлне яхшырта. Әмма хөкүмәтнең финанс блогында артык көчле сумны яратмыйлар бер дә, чөнки кыйммәтле валюта сатып, бюджетны тутырырга ияләнделәр. Эчке базарда үзебез җитештергән товарларның кыйммәтләнүе дә бюджетка файда ул, уйлап карасаң. Кыйммәткә сатылган товар салымны да мулрак китерә. Менә шундый каршылыклар көрәше пәйда булды. Валютаның ныгуы яхшы да, начар да, бәяләр күтәрелү дә шулай ук. Алтын урталыкны эзләргә туры килә.

Валюта ныгуның объектив сәбәпләре күп. Бердән, төп ставка чамасыз югары. Бу халык кулындагы акчаның бер өлеше товар алуга да, доллар-евро сәүдәсенә дә түгел, депозитларга китә дигән сүз. Экспорт табышы арту турында әйттек инде. Чикләүләр импортның бик нык кимүенә китерде. Долларның бик кыйммәт йөрүе дә импортны файдасыз итә иде. Кыйммәтле чит ил товарларын сатып алучылар аз булачак бит.

Биржада валюта сатып алучы брокерларга да чамасыз зур комиссияләр түләргә туры килде. Күләме башта 30 процент иде, аннан соң 12гә кадәр йомшартылды. Иң мөһиме: физик затларга банклардан валюта сатып алу мөмкинлеге юк иде. «Җитмеш биш сумга доллар сатасызмы?» «Юк, күрсәтәбез генә», – дигән анекдот да тудырды бу хәл. Күләргә була, әлбәттә, әмма чит илгә җыенгансың, билетың бар – кесәңдә валютаң юк икән, елыйсы да килергә мөмкин. Төрек банклары «Мир» картасы аша бер долларга ике йөз сум түләп, валюта алыштырырга мөмкинлек бирә башлады. Кайбер Урта Азия илләрендә соңгы көннәрдә йөз егерме сумнар тирәсенә доллар алып була дип әйтәләр иде.

Үзәк банк, ниһаять, долларның чын бәясен ачыкларга булды. Башта төп ставка бераз төшерелде, валюта алганда, брокерлар түли торган комиссияне дә бөтенләй бетерергә җыеналар. 18 апрельдән банкларга валюта сату да рөхсәт ителә башлый. Ләкин банклар үз кассаларына 9 апрельдән соң кергән валютаны гына сата алачаклар. Моның бер нечкә ягы бар: илгә кәгазь долларлар һәм евролар кертү тыелды бит. Шулай булгач, банклар «тере» валютаны каян алалар? Гражданнар үз кесәләрендәге валютаны сатса гына. Менә мондый вазгыятьтә банкларда валюта курсының ничек буласын әйтү бик кыен.

Бер нәрсәне истә тотарга кирәк: илгә килә торган валюта елгаларының ташуы – вакытлы күренеш. Бердән, углеводородларга бәя төшү ихтималы да юк түгел, икенчедән, Россиядән аларны алуны киметергә җыеналар. Шулай булгач, акчасы барлар бераз валюта запасы булдырса, зыян итмәстер, мөгаен.

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ИҢ ЯХШЫСЫ – УКЫТУЧЫГА

tatarstan.ru

Компьютерлар Лаешта җыела. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов, Усад авылындагы «ICL Техно» техника җитештерү заводында булып, тармак белгечләре белән аралашып, замана техникасын ничек ясауларын карап кайтты.

«ICL – КПО ВС» җәмгыятенең директорлар советы рәисе Виктор Дьячков җитештерелә торган продукция белән таныштырды, үсеш мөмкинлекләре турында сөйләде, 2017–2021 елларда сатылган продукция турында санлы мәгълүмат китерде. Президентка компьютерның төп платосы (материнское плато) проектын да күрсәттеләр.

Соңрак Рөстәм Миңнеханов укытучыларга Татарстанда җитештерелгән Raybook ноутбукларын тапшыруда катнашты. Замана техникасының унысын бу юлы информатика һәм мәгълүмат технологияләре юнәлеше буенча махсус олимпиадаларда җиңүчеләрне әзерләгән мөгаллимнәргә бүләк иттеләр. Бу – «ICL – КПО ВС» компаниясе җитештергән техника. Аның эчлеге, ягъни программалар җыелмасы да Россиядә җитештерелгән, Microsoft Office продукциясенә алмаш булып тора.

– «ICL – КПО ВС» компаниясе өчен дә бу – яңа шартларда эшләргә өйрәнү, импортны алмаштыруга бәйле таләпләргә күнегү. Гомумән, компания җитди эш алып бара, хәзерге вазгыятьтән чыгу юлын табарга ышаныч бирә, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Гомумән алганда, укытучыларга 12 мең ноутбук биреләчәк. Бу – мәгариф тармагына җитди ярдәм.

Шул җәһәттән республика Президенты «Ак Барс» банкына да рәхмәтен әйтте. Әлеге эш алар ярдәме белән башкарыла.

«Ак Барс» банкы идарәсе рәисе Зөфәр Гәрәев билгеләп үткәнчә, банк өчен бу – социаль җаваплылык сәясәтенең бер өлеше. Яңа ноутбуклар искергән техниканы алмаштырырга мөмкинлек бирәчәк.

– Алга таба да шундый ярдәм күрсәтеләчәк. Әлбәттә, кыйммәткә төшә торган эш, әмма сыйфатлы белем бирү цифрлаштырудан башка була алмый. Бу ноутбукларга ихтыяҗ бар, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин тармакка күрсәтелгән ярдәм өчен республика җитәкчелегенә рәхмәтен әйтте.

– 2010 елдан 2018 елга кадәр «Укытучыга – ноутбук» проекты кысасында республика бюджеты хисабыннан 90 меңнән артык ноутбук сатып алынды. Цифрлаштыру елында республика укытучыларына ноутбуклар алыштыру турында карар кабул ителде, аларны бүгеннән тапшыра башлыйбыз. Барлык мәктәпләр дә диярлек югары тизлекле интернет белән тәэмин ителгән, Wi-fi нокталары бар, – диде министр.

Космонавтика көне белән!

Татарстан Премьер-министры Алексей ПЕСОШИН республикада яшәүчеләрне Космонавтика көне белән котлады.

«Галәмне өйрәнү төрле фәнни һәм техник тармакларда алгарышка китерә, инвестицияләргә яңа ихтыяҗлар тудыра, – диелә котлауда. – Галәм эшчәнлеге шулай ук белем дәрәҗәсен тиешле биеклектә тотуны таләп итә. Моннан тыш галәм киңлекләрен тикшерү тулаем ил икътисадын алга таба этәрүче көч булып тора, чөнки бу – иң югары технологияле тармакларның берсе.

Татарстанда яшь буын илебез космонавтикасының башында торган атаклы галимнәр һәм практиклардан эстафетаны лаеклы төстә кабул итсен өчен кирәкле барлык шартлар тудырыла. Табигать фәннәре белән кызыксынучы иң зиһенле, иң тырыш егетләр һәм кызларыбыз киләчәктә мөһим ачышлар ясарга мөмкин. Әлеге үтә әһәмиятле эшне, укучылары белән бергәләшеп, мәктәпләр һәм кванториумнар, балалар иҗат йортлары түгәрәкләре һәм секцияләре укытучылары башкара. Нәкъ менә шулар яшьләрдә астрономиягә, физика, математика һәм башка төгәл фәннәргә карата мәхәббәт тәрбияли.

Кешелек тудырган сәбәпләр аркасында килеп чыккан чирләр, низаглар, табигать көйсезлекләренә каршы көрәшү өчен әйләнә-тирә мохит турында белемне даими киңәйтеп торырга кирәк. Галәмне өйрәнүнең төп максаты шунда да».

Сүтеп җыю гына түгел

Холыкны ныгыта, тәртипкә өйрәтә. Казанда егетләрдә әнә шундый асыл сыйфатлар тәрбияләячәк «Авангард» хәрби-патриотик укыту-методик үзәге ачылды.

Ул «Патриот» республика үзәге карамагында эшләячәк. Республика мәктәпләрендә 10 нчы сыйныфта укучы бер төркем егет башкалага биш көнлек җыенга җыелды. Ел дәвамында Казанда тагын шундый биш смена эшләячәк. Аларның һәркайсында 200дән артык кеше катнашыр дип көтелә.

Казанда өлкән сыйныфта укучы малайлар өчен яңа хәрби-патриотик үзәк ачылачагын белгәч, күп кенә ата-аналар арасында яшен тизлегендә имеш-мимешләр таралды. Тантаналы ачылышка килгән җитәкчелек беравыздан уйдырмаларны инкарь итте. «Әлеге җыен Украинадагы хәлләр белән һич кенә дә бәйле түгел. Ел саен уку елы азагында өлкән сыйныфта укучы егетләр өчен тормыш иминлеге нигезләре фәне кысасында шундый хәрби-патриотик җыеннар уздырыла бит», – дип тынычландырды Татарстанның мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин.

Билгеле булганча, узган ел Россия Президенты Владимир Путин илнең һәр төбәгендә хәрби-патриотик тәрбия эше белән шөгыльләнүче «Авангард» исемле махсус үзәк булдырырга кушты. Татарстанда исә бу эш күптәннән алып барыла инде. Ел саен май аенда 10 нчы сыйныфта укучы егетләр биш көнгә табигатькә чыгып, палаткалар корып, хәрби тормыш нигезләренә төшенеп кайта. Хәзер исә бу эш зур бер үзәк кысасында башкарылачак.

«Авангард» үзәгендә уздырылган биш көнлек җыен вакытында егетләр марш атларга, корал сүтеп җыярга, беренче ярдәм күрсәтергә өйрәнәнәчәк, теоретик белемнәрен дә ныгытачак. Моннан тыш алар физик һәм рухи яктан ныгый, яшьтәшләре белән аралаша ала. «Патриот» үзәгендә егетләргә яшәү, хәрби күнекмәләргә өйрәнү өчен бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган. Үзәк җитәкчесе Дмитрий Литвинов, бирелә алган белем-күнекмәләр егетләрне гомер буе озата барачак, дигән фикердә. «Хәрби генә булырга димәгән. Җыенда алган күнекмәләр егетләргә нинди генә һөнәр сайласа да кирәк булачак», – ди ул.

«Авангард» үзәгенең беренче җыенына, нигездә, республиканың кадет мәктәпләрендә укучы малайлар җыелган иде. Алга таба бирелә гадәти мәктәпләрдә укучы егетләр дә катнашачак. Ел дәвамында мондый хәрби-патриотик җыеннарда республика күләмендә 8 меңләп егет катнашыр дип көтелә. Кадет мәктәпләрендә укучы егетләр хәрби тормышның егет кешегә ни дәрәҗәдә йогынты ясавына төшенергә өлгергән инде. Тәтеш кадет мәктәбендә укучы Сергей Соловьев тәртипкә өйрәнгән әнә. «Кадет мәктәбе, мондый җыеннар тәртипкә өйрәтә, холыкны ныгыта, дөньяга караш үзгәрә. Мондый җыеннарда һәр егет катнашырга тиеш», – дип сөйләде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Якын киләчәктә республикада тагын ике «Авангард» үзәге пәйда булачак. Алар Түбән Кама һәм Чистай районнарында ачылыр дип көтелә. Әлегә бирелә төзекләндерү эшләре бара. Сентябрьдән исә әлеге үзәкләрдә дә хәрби-патриотик җыеннар уздырылачак.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

КҮКТӘН ТӨШКӘННЕ КӨТӘСЕ ТҮГЕЛ

Язгы чәчү

Шамил аганы тиз генә табарлык түгел. Тормыш иптәше Роза апа да, уенын-чынын бергә кушып, Шамил абыегызны үземнең дә күргәнем юк әле, ди. Сәбәбе – иртәдән кичкә кадәр кырдан кайтып керми тәҗрибәле агроном. Илле дүртенче язын көн саен Лаеш районы Хәерби авылы кырларын бер әйләнмәсә, күңеле булмый бугай. «Кояш үзе кырга тартып чыгара», – дип шаярта. Роза апа әйтүенчә, кыш көннәрендә барып та кар астындагы игеннәрнең хәлен белеп кайта.

Татарстанның һәм Россиянең атказанган агрономы Шамил ага Кушмин язгы кыр эшләренең беразга тоткарлануын хәерлегә юрый.

– Узган ел 30 мартта җирне тырмалап, эшкәртеп, чәчүгә керешкән идек. Быел кар күп, шуңа бераз тоткарланырга туры килә. Аның каравы көзге культуралар бик яхшы сакланган. Узган елдагы кебек, яңадан чәчәргә туры килмәстер, шәт. Кырлар тиз ачыла үзе, тик техника кертергә иртәрәк, җир юеш әле. Атна ахырына барлык эшләрне дә башларбыз дип өметләнәм, – ди Шамил ага.

Борчулары да җитәрлек. Орлыкка, ашлама, запас частьлар һәм башка кирәк-яракларга бәя күтәрелүенә ничек борчылмыйсың ди? Чәчүлек орлыклар, шул исәптән борчакның килограммы 30 сумнан арткан. Ярый әле, Хәерби хуҗалыгы орлыкларны үзе җитештерә. Яңарак кына 60 тонна чәчүлек орлык сатканнар. Димәк, ашламаны күбрәк кертергә мөмкинлек булачак.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бүгенге бәяләр Хәерби хуҗалыгы кебек мөстәкыйль эшләргә омтылучыларның гына түгел, эре хуҗалыкларның да тез астына нык суга. Язгы культураларны 48 мең гектарда чәчәргә җыенучы хуҗалык җитәкчесе Марат Хәсәнов сүзләренә караганда, дәүләт ярдәменнән башка бу кадәр эшне башкарып чыгу мөмкин түгел. Ярый әле 10 мең гектардан артыгын көздән чәчеп калдырганнар. «Дым күп, тиешле күләмдә ашлама да кертсәк, быел мул уңышка өмет бар», – ди Марат Хәсәнов.

Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Наил Залаков әйтүенчә, республика хуҗалыклары язгы культуралар чәчү өчен кирәк булган орлыклар белән 115 процентка тәэмин ителгән. Шуның 97 проценты югары кондицияле булу аеруча сөендерә. Сыйфатсыз орлыктан мул уңыш алып булмаячагы алдан ук билгеле.

Язгы кыр эшләренә әзерлек чорында игенчеләрне иң борчыганы – ашламалар туплаудыр, мөгаен. Кырлар кардан арынгач та, күпьеллык һәм көзге культураларны үз вакытында азотлы ашламалар белән тукландыру кирәк. Шуны яхшы аңлаган игенчеләр матди кыенлыкларга да карамый, кыш дәвамында хуҗалыкларда ашлама туплау белән шөгыльләнде. Наил Залаков әйтүенчә, республика буенча бүген хуҗалыкларда 152 мең тонна күләмендәге тәэсир көченә ия ашлама бар. Бу исә – бер гектарга уртача 55,1 килограмм туры килә дигән сүз. Аз, әлбәттә. Игенчелек алга киткән илләрдә бу күрсәткеч берничә тапкыр күбрәк. Бу эш соңгы вакытларда аеруча актив алып барыла. Ел саен мул уңыш алучы хуҗалыкларда быел да ашлама күләме 90 килограмм һәм аннан да артып китә. Тәтеш һәм Зәй районнары хуҗалыкларында гектарына 100 килограммнан артык ашлама тупланган. Ә Балык Бистәсе (25,3 кг), Әгерҗе (15,1 кг) һәм кайбер башка районнарда уңыш күләме ни өчен елдан-ел кими баруына быел да гаҗәпләнәсе булмастыр, шәт.

Орлык, ашлама һәм башка кирәк-яраклар җитәрлек дәрәҗәдә әзерләнеп тә, язгы кыр эшләрендә катнашырга тиешле техника һәм техник җайланмалар вакытында төзәтелмәсә, иң кирәк чагында гына ватылып азапласа – игенче өчен иң кыены шул бугай. Кыш дәвамында хуҗалыкларда ай саен диярлек уздырылган төрле семинарлар, үзара киңәшү, уңай тәҗрибә уртаклашуның тәэсире булмый калмагандыр. Министрлык вәкилләре әйтүенчә, бүген барлык техниканың 98 проценты язгы кыр эшләрен төзек килеш каршылый. Дөрес, әлегә 108 трактор, 20 чәчү комплексын төзәтеп бетерәсе бар барын. Әмма, теләк булганда, бу кадәресе хәл итә алмаслык проблема түгел.

Язгы кыр эшләрен вакытында һәм югары сыйфат белән башкарып чыгар өчен миллиардларча сум акча кирәк. Республика буенча бары запас частьлар алыр өчен генә дә хуҗалыкларга 2 миллиард 100 милион сумлык чыгымнарга барырга туры килгән. Чыгымнар никадәрле генә күп булмасын, акчасыз кыр эшләрен башкарып чыгып булмый. Наил Залаков әйтүенчә, акча табуның иң үтемле юлы – кыска вакытлы кредит ресурсларын рәсмиләштерү. Бүген республиканың 132 хуҗалыгы әлеге мөмкинлектән файдалана алган. Алынган кредитка дәүләт биргән субсидия акчасы гына да 1 миллиард сумнан арта, ди министр урынбасары. Шул ук вакытта, кыска вакытлы кредитлар белән бәйле 285 миллион сум субсидия әлегә үз хуҗасын көтә.

Дәүләт ярдәме дигәннән, 70кә 30 схемасы белән техника алган хуҗалыкларга 28 марттан башлап субсидия алу мөмкинлеге бар. Беренче чиратта, 2019–2020 елларда алынган техникага субидия бирү карала. Әлеге максатларда 1 миллиард 200 миллион сум акча каралган. Октябрь аена планлаштырылган икенче этапта 1 миллиард 100 миллион сум субсидия биреләчәк, ди министр урынбасары.

Дөрес, хуҗалыкларга бирелергә мөмкин булган дәүләт ярдәмен, төрле субсидия һәм дотация акчаларын алу җиңел түгел. Аларның һәркайсы төрле яклап исәпләү, күп төрле кәгазь һәм документлар әзерләү белән бәйле. Әмма, күктән төшкәнне көтеп, үзең әлеге юнәлештә бармакка бармак сукмасаң, анысын да алуы кыен.

Камил СӘГЪДӘТШИН

БАЛА КҮҢЕЛЕН КЕМ АҢЛАР?


pixabay.com

Яшәеш

Гаиләдә төрле хәлләр була. Кайчак сабыр канатлары сына һәм ир белән хатынга бары тик бер юл – аерылышу кала. Шул чакта балага ничек ярдәм итәргә? Бу хакта Татарстан Дәүләт Советының «Мәрхәмәт» һәм Казан шәһәр Думасының «Өмет» хатын-кызлары оешмалары катнашында узган «түгәрәк өстәл»дә сөйләштеләр.

Республикада быел өч айда, узган ел белән чагыштырганда, аерылышучылар саны 7 процентка кимегән. Татарстанның ЗАГС идарәсе җитәкчесе Гөлшат Нигъмәтуллина сүзләренә караганда, балигълык яшенә җитмәгән бала үстерүче гаиләләр арасында да аерылышу очраклары кимү күзәтелә икән. «2019 елда 11628 мең гаилә таркалган булса, узган ел 9585 мең очрак теркәлгән», – диде ул.

Гөлшат Нигъмәтуллина яшь гаилә бергә яшәүнең беренче 5–10 елында аңлашылмаучанлыклар кичерә дигән фикердә. Шунлыктан аерылышуларның 60 проценты нәкъ менә шушы вакыт арасында теркәлә икән.

– Күп очракта аерылышырга теләвен хатын-кыз җиткерә. Сәбәпләрен бер-беребезне аңлый алмыйбыз, хыянәт, ирем матди хәлне кайгыртмый дип аңлаталар. Тиз генә карар кылалар да аерылышырга гариза илтәләр. Ашыкмаска кирәк, – ди ул.

Татарстанның Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкиле Ирина Волынец фикеренчә, гаиләдә балигълык яшенә җитмәгән бала булса, аңа психологик ярдәм күрсәтергә кирәк. Баксаң, ата-ананың аерылышуы стресс дәрәҗәсе буенча үлемнән кала икенче урында тора икән.

– Әгәр ата белән ана аерылышырга теләсә, алар психологлардан ярдәм сорарга тиеш. Моны мәҗбүри итәргә кирәк. Чит илләрдә мондый алым кулланыла. Болай эшләү баланың психикасын саклар иде. Европа илләрендә әлеге хезмәт өчен 1,5–2 мең евро түләргә кирәк. Ә бездә бушлай оештырыла, – ди Ирина Волынец.

Очрашуда төрле фикерләр яңгырады. «Әтиләр союзы» вәкилләре дә чыгыш ясады. Алар «Җаваплы әти-әни мәктәбе» проектын тәкъдим итте. Яшьләр өйләнешкәнче үк, гаилә өчен җаваплы, балалар алдында бурычлы икәнен белергә тиеш, ди алар. Гаилә кыйммәтләре турында да сөйләргә киңәш итәләр.

Казанның Совет районы опека һәм попечительлек бүлеге җитәкчесе Ирина Смирнова да бала язмышы белән уйнамаска өнди.

– Күп очракта суд карары үтәлми. Әни кеше баласын әтисенә күрсәтергә теләми яки, киресенчә, әти кеше каршылык күрсәтә. Кая барырга белмәгән бала зур стресс кичерә. Үз эченә бикләнә, тормышка карашы үзгәрә. Тулы булмаган гаиләдә үскән бала үзе дә ныклы оя кора алмый, – ди ул.

Казан шәһәр Думасының «Өмет» хатын-кызлар оешмасы җитәкчесе Людмила Андреева, Гаилә кодексы һәм Суд кодексына үзгәрешләр кертергә кирәк, дигән тәкъдим белән чыкты. Алар бу уңайдан Дәүләт Думасына мөрәҗәгать итәчәкләр.

– Без бу теманы күптән күтәрәбез. Әлбәттә, шәһәр Думасы көче белән генә бу сорауны хәл итә алмыйбыз. Безгә федераль дәрәҗәгә дә чыгарга туры киләчәк, – ди ул. – Хәзер бит судлар читтән торып та үтә. Балалар үстергән гаилә өчен болай эшләү дөрес түгел. Моны судьялар да аңлый, әмма законга каршы бара алмыйлар. Аерылышканда бала бүлә алмау очраклары да бар. Психологлар бу ата-аналар белән сабыйлары язмышы хакында сөйләшергә тиеш. Балага кем белән яшәү яхшырак булу турында белешмә биргәнче, аерылышу процессы тукталып торырга тиеш. Моның өчен закон кирәк.

Дәүләт Советы хатын-кыз депутатларының «Мәрхәмәт» оешмасы җитәкчесе Алсу Нәбиева әйтүенчә, аналарны һәм балаларны яклау мәсьәләләре – һәрдаим парламентның игътибар үзәгендә. «Очрашуда ата-аналар аерылышкан вакытта баланың ниләр кичергәнен аңлаган кешеләр катнашты. Минемчә, бу – җитди эшнең башы гына әле. Киләчәктә без бу теманы дәвам иттерәчәкбез», – диде ул.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

«ВАКЫТ ҖИТТЕ КЕМНЕҢ КЕМ ИКӘНЕН АКЫЛ КӨРӘШЕНДӘ ИСБАТЛАРГА»

Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясенә кандидатлар

«Казан утлары» журналының сентябрь саны минем фикерләвемне төптән үзгәртте дисәм дә, ялган булмас. Мин әле хәзер дә Флера Гыйззәтуллинаның көчле поэзиясе белән тәүге тапкыр танышуымнан эчке бер ләззәт кичерәм. Чын күңелемнән «Коллык зинданы» поэмасы хәзерле әдәбиятның алтын ядкярләре рәтендә булыр дип ышанам.

Сезнең һәммәгезгә дә Флера Гыйззәтуллинаның «Чишмә юлы» (1974), «Сәлам хаты» (1981), «Акчарлагым – асыл кошым», (1983), «Утлы минутлар» (1986), «Сер ачкычым сердәштә» (1990), «Яшеннәрнең күз яше» (1995), «Йөрәгемдә шаулый карурман» (2001), «Күз нурларым» (2002), «Башкаемда дөнья исәпләре» (2007), «Яну дәверләрендә» (2013) җыентыкларын укып, бу шигъриятнең чиста һәм көмештәй саф чишмәсенә кагылырга киңәш итәм. Иманым камил: шагыйрәнең сәнгати сурәтләр «карурман»ына сәяхәт итеп, сез дә бик күп ачышлар ясарсыз һәм аның ялкынлы йөрәгенең кайнар энергиясеннән көч алырсыз.

Мин шагыйрәнең университет китапханәсендә булган бар шигъри җыентыкларын бик зур соклану белән укып чыктым. Шулай итеп «Казан утлары»на шагыйрәнең иҗаты турында мәкалә язылды (2021, № 11). Берничә ай буе «Яну дәверләрендә» китабының эзенә төшә алмыйча йөрдем. Ленар Шәехкә рәхмәт, ул миңа бу китапны табып бирде. Мин Флера Гыйззәтуллинаның сафландыргыч утлы учагы аша үтә алуым белән чиксез горурланам.

Жанр ягыннан бу әсәр – поэма-трилогия. Бу китапның иң зур кыйммәте – аның көчле тарихи яңгырашка ия булуында. Флера Гыйззәтуллина татар халкы тарихындагы драматик вакыйгаларны яңадан торгыза һәм хәзерге көнгә күперләр сала. Бу «көзге»гә карап, укучы заманның актуаль проблемаларын аңлый, үзенең рухи дөньясын бәяли, киләчәккә планнар кора.

Арзан мелодраматизмнан качарга тырышып, Флера Гыйззәтуллина гражданлык юлын сайлый, укучыда «Ватан» турында төгәл төшенчә булдырырга омтыла. Бу төшенчәнең мәгънәви чикләре бабаларыбыз тарафыннан героик сугышларда формалашкан. Шагыйрә әлеге сакраль киңлекне «Коллык зинданы»на әйләндерүгә каршы чыга. Ул «базар икътисады» елларында халкына ышанычын җуйган, акча колына әверелеп, милли кыйммәтләргә кызыксынуын югалткан замандашларының күзләренә борчылып карый.

Поэманың авторы үзен халкына рухи бишек җырын җырлаучы ана итеп күзаллый, ул «киләчәккә васыять» әйтә: *«Бишек җыры көйләп, үз баласын / Ап-ак биләүләргә биләгәндә, Ирен, Ватанын да били Ана. / Шундый Аналарның берсе мин дә – Илем васыятен салдым иңгә».* Ул татар моңының, үз көченең терелтүче көченә ышана: *«Моң күтәргән Илне көрәш үренә»,* – дип яза.

Поэманың буеннан-буена татар халкының ирек яратучан рухи темасы сузыла. Флера Гыйззәтуллина, халык образы тере сурәткә әверелсен өчен, поэмада күп тапкыр танылган кешеләрнең исемнәрен санап үтә:

...Җыен ярышында һәр җанатар
Рухи өстенлектә ләззәт татый:
– Әнә! «Прометей»ны куып үтте
«Идегәй!»
«Сал-Сал!»
«Нури!»
«Нәкый!»
«Бакый!»
– Әнә «Сөембикә!»,
«Сафагәрәй!»
Уктай оча ут мәхшәре аша...
Күрәчәктән тулып таша-таша,
Үз ирекен милләт үзе ача.

Халкыбыз тарихының драматизм белән сугарылган битләрен актарып, баһадир ата-бабаларыбызның данына лаек булмаган битлек кигән замандашларын тәнкыйть утында яндыра:

Безнең милли кыйбла ирегендә
Ак барс һәм кара елан тора.
Ватанымның моң һәйкәле булып,
Кара төн һәм кара урман тора.
Урман ешлыгында очрап тора:
«Аю»,
«Бүре»,
«Куян»,
«Керпе»,
«Төлке»...
Безнең «Ирек!» диеп михнәт чигү
Бу затларның һәммәсенә көлке!

Поэма авторы дөньяга Кол Гали, Кол Шәриф, Тукай, Җәлил бүләк иткән халыкны данлый... Үз фикерен төгәлрәк белдерү өчен, шигырь юлларының график һәм семантик сәнгати потенциалыннан оста файдалана. Ул һәркем үзенең туган җире белән аерылгысыз бәйләнешен сизсен һәм, тарих учагы тирәсендә торып, үзенең рухын ныгытсын дип хыяллана.

Флера Гыйззәтуллинаны «Ватан» төшенчәсенең, тараеп, кече ватанга трансформацияләнүе һәм котылгысыз рухи югалтулар проблемасы борчый... Шуңа күрә поэма авторы хәтер учагының сафландыргыч ялкыны образын тагын да кабарта. Татар дәүләтчелеген ул канатлы тулпар образы белән тиңли: «Азатлык ул каян баш алса, Көмеш тояк кагып йөргән атта». Шагыйрә бу яңартылган процесста Суверенитет дәверен һәм Минтимер Шәймиевнең ролен югары бәяли.

Поэманың икенче өлешендә зур тарихка үзенең биографиясен дә кертә. Аның илһам чыганагы – тормыш үзе, ә аның үлчәү берәмлеге – «сугыш балалары» буыныннан булган шагыйрәнең шәхси язмышы. Аның шигърияте – туган җиргә мәңгелек табыну урыны. Тормыш шагыйрәдә мәңгелек яну белән тиңләштерелә, аның ялкынын һәр кеше җанындагы утлы энергетика саклый. Тукай традицияләренә тугры калып, ул үз тормышын милләт язмышы белән бер киңлектә карый: «Минем вөҗдан – милләт вөҗданы ул!» («Хаклык»). Суверенитет идеаллары белән канатланган шагыйрә үз халкын ирекле һәм бәйсез, уңышка ирешә һәм үз-үзен тәэмин итә алырлык итеп күз алдына китерергә хыяллана.

Поэманың өченче өлешендә Флера Гыйззәтуллина татар рухының төп мифологемаларын торгыза, милли характерны барлыкка китерүче төп сыйфатларны тарихи контекстка куеп өйрәнә. Биредә шагыйрьнең монологы милләт геройларының күп тавышлылыгы фонында эпик мәгънәгә ия. Аңа киләчәк буыннарның, тарихи хәтер диңгезенә чумып (чаг. *«Ил хәтере – тирән диңгезләр...»*), дөрес милли ориентирлар, үзенчәлекле маяклар табуы мөһим.

Поэма-трилогиядә Флера Гыйззәтуллинаның шигъри осталыгы бөтен матурлыгында чагыла. Ул татар шигъри традициясенең халык шигыреннән күптөрле хәзерге заман формаларына үсешен, эволюциясен ачык күрсәтә. Шагыйрәнең бер шигъри техникадан икенчесенә күчүдәге җиңеллеге һәм осталыгы да мактауга лаек.

Флера Гыйззәтуллинаның шигырьләрен укыганда, без замана кешесенең киң һәм хәрәкәтчән сөйләм стихиясе белән баетылган теленә чумабыз. Аның тарихи-фәлсәфи поэмасы, авторлык хисләре һәм фикерләренең барлык бәйләнешләрен ачып, ниндидер махсус фәлсәфи яки сәяси сүзлектән файдаланмыйча, бик табигый һәм сыгылмалы итеп ачыла. Ул, артык «көчәнмичә», бик табигый итеп, шигъриятендә Г. Тукайның лирик моңын, Дәрдемәнд медитацияләренең югары ешлыгын, М. Җәлилнең милли-патриотик мотивларын, Һ. Такташның ораторлык осталыгын берләштерә. Шагыйрә үзенең асылын халкы алдындагы гражданлык бурычын үтәүдә күрә. *«Вакыт җитте кемнең кем икәнен / Акыл көрәшендә исбатларга»* дигән шигарьгә без «Флера Гыйззәтуллина «Яну дәверләрендә» поэма-трилогиясе (2013) өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты булырга лаек!» дип җавап бирәбез.

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,
әдәбият галиме

КОТЛЫЙБЫЗ!

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге әйдәүче белгече – эксперты **Акименко** Елена Анатольевнага; Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Түбән Кама районы буенча 2 номерлы суд приставлары бүлекчәсе әйдәүче суд приставы-башкаручысы **Хәсәншина** Әлфия Азиз кызына; Татарстан Республикасы Сарман район суды администраторы **Александров** Николай Петровичка; «Суд эшчәнлеге» дәүләт автоматлаштырылган системасын тәэмин итү мәгълүмат-аналитика үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасындагы филиалы инженеры **Сибгатуллин** Илгиз Илдус улына; «Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Ведомстводан тыш сак идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы – Балтач районы буенча ведомстводан тыш сак бүлекчәсе башлыгы **Ганиев** Ришат Рәшит улына; Татарстан Республикасы прокуратурасының гомуми һәм махсус эш башкару бүлеге әйдәүче белгече **Җантимерова** Сания Хәнифулла кызына; «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Аппараты» муниципаль казна учреждениесенең җәмәгать куркынычсызлыгы мәсьәләләре һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы **Кузнецов** Николай Владимировичка; «Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» дәүләт бюджет учреждениесенең баш энергетигы бүлеге башлыгы (баш энергетигы) **Шуркина** Әлфия Сабирҗан кызына; «Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы» дәүләт бюджет учреждениесенең бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы **Яковлева** Светлана Азат кызына; Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Назарова** Ирина Викторовнага; Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Садыйкова** Людмила Алексеевнага; **Шәфиков** Рифкать Зыятдин улына; «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Иске Ибрай урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең физик культура укытучысы **Бикушев** Рәис Харис улына; «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Олимп» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе директоры **Хисамов** Рифат Револь улына; Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгы **Емельянов** Юрий Ивановичка; «Казан дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесесе баш режиссеры ярдәмчесе – труппа мөдире **Лукина** Любовь Николаевнага; «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Йосыпова** Мәрьям Хәмзә кызына; Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе Питрәч һәм Балык Бистәсе районнары буенча муниципальара бүлеге башлыгы **Тиханова** Эллина Александровнага; Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгы **Фәршатова** Гөлчәчәк Гыйздулла кызына; Казан «Органик синтез» гавами акционерлык җәмгыятенең спортның су төрләре буенча «Синтез» спорт клубы коллективына; «Казан дәүләт энергетика университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе ректоры **Габдуллаҗанов** Эдвард Юныс улына **Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәтен** белдерелде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Казан шәһәре Идел буе районының «100 номерлы урта гомуми белем бирү мәктәбе – Мәгариф үзәге» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Абдуллина** Рәхилә Дамир кызы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе **Ганиев** Ильяс Рәсим улы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының мәгариф һәм фән комиссиясе рәисе урынбасары **Гыйльмиева** Римма Хәмит кызы, «Таганрог элемтә фәнни-тикшеренү институты» акционерлык җәмгыяте генераль директоры **Марченко** Игорь Александрович, «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең үз хәбәрчесе **Сәгъдәтшин** Камил Шәмгун улы, Казан шәһәре Вахитов районының «Татар телендә белем бирелә торган 27 номерлы гимназия» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Хөснетдинова** Люция Габһади кызы, Казан шәһәре Идел буе районының «17 номерлы төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе директоры **Шаһиева** Әлфия Рәшит кызы; җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен «Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләренең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча Ведомстводан тыш сак идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесе филиалы – Казан шәһәре буенча ведомстводан тыш сак идарәсе (Идел буе районы буенча) 2 нче полиция батальоны (аерым) командиры, полиция подполковнигы **Андреев** Евгений Николаевич; Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасының «Татарстан китап нәшрияты» дәүләт унитар предприятиесе мөхәррире, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» җәмәгать оешмасы (Иҗат берлеге) әгъзасы **Гыйльманов** Галимҗан Хәмитҗан улы; Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Авторетроклуб-21» тарихи техника һәвәскәрләр клубы» автоһәвәскәрләрнең Татарстан Республикасы төбәк иҗтимагый оешмасы әгъзалары: **Гнедин** Александр Васильевич, **Җамалиев** Айрат Ингел улы, **Ибәтуллин** Айдар Фәрит улы, **Садретдинов** Фарул Кашаф улы, **Яруллин** Риф Лотфулла улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «ТаграС-Холдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте идарәсе рәисе, «ТаграС- Холдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Нәҗипов** Ленар Лим улы «**Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

***

«Түбән Кама шәһәре дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы – баш ветеринария табибы **Әгълиуллин** Илназ Кәрим улына **«Татарстан Республикасының атказанган ветеринария табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Республика медицина мәгълүмат-аналитика үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең белешмәләр базасын туплау бүлеге мөдире **Вәлиева** Диларә Рафаил кызына, «Кама Тамагы үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең Кече Салтык фельдшер-акушерлык пункты фельдшеры **Володягина** Роза Ивановнага, «Нурлат үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе поликлиникасының онкология кабинеты шәфкать туташы **Галиуллина** Гөлсирә Мансур кызына, «Биектау үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең ашыгыч медицина ярдәме бүлекчәсе фельдшеры **Гритчина** Антонина Николаевнага, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В.М.Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрия хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең социаль хезмәт күрсәтү бүлеге мөдире – социаль эш белгече **Дагаева** Ольга Владимировнага, «Питрәч үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең педиатрия бүлекчәсе өлкән шәфкать туташы **Максимова** Наталья Николаевнага, «Тәтеш үзәк район хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе ашыгыч медицина ярдәме бүлекчәсенең ашыгыч ярдәм күрсәтүче өлкән фельдшеры **Сәфәров** Руслан Валерьевичка **«Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Е.Ә. Тимерҗанов исемендәге «Юность» спорт мәктәбе» муниципаль автоном учреждениесе бүлекчәсе мөдире **Бородин** Владимир Николаевичка, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең көрәш буенча тренеры **Нургалиев** Ришат Әбүдәр улына, «Батыр» олимпия резервы республика спорт мәктәбе» дәүләт автоном учреждениесенең өлкән инструкторы-методисты **Сәлахиева** Резеда Равил кызына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «1 номерлы спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесенең җиңел атлетика буенча тренеры **Төхбәтуллин** Фәнил Фәрит улына **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Хуҗалык идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенең исәп һәм хисап бүлеге баш белгече **Алиева** Рамилә Зөфәр кызына, «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе **Макаров** Алексей Николаевичка, Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары **Мәхмүтов** Марсель Азат улына, «Алойл» ябык акционерлык җәмгыятенең финанс-икътисад бүлеге башлыгы **Хәбибуллина** Зөлфия Камил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасы Югары Судының отставкадагы судьясы **Әхмәтшина** Аида Шамил кызына; Татарстан Республикасы Лаеш районы прокуроры өлкән ярдәмчесе **Васильева** Миләүшә Ивановнага; Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы киңәшчесе **Туркенич** Алина Яковлевнага; Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы киңәшчесе **Шәмсетдинова** Эльмира Мурат кызына; «Түбән Кама нефтехим» гавами акционерлык җәмгыяте генераль директорының икътисади куркынычсызлык, сак һәм режим буенча урынбасары **Гатин** Руслан Рафикъ улына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

Аттестат об основном общем образовании за 9 класс на имя Нефедова Александра Олеговича, серия 16 ББ, номер 0055028, выданный средней общеобразовательной школой № 8 г. Казани 17.06.2008 года, считать недействительным в связи с утерей.

Ярыш

Алар яхшырак та булдыра

ТАТАРСТАНДА «АБИЛИМПИКС» ЧЕМПИОНАТЫ БАШЛАНДЫ

Сәламәтлекләре чикләнсә дә, күңелләре һәм мөмкинлекләре – юк. Алар компьютер серен дә белә, зәркән эшләнмәләр дә ясый, аш-суда да оста. Бу арада кабат осталыкларын дәлилләргә җыеналар. Татарстанда физик мөмкинлекләре чикле кешеләр өчен «Абилимпикс» төбәк чемпионаты узачак. Иң-иңнәрне исә Мәскәү көтә. Оештыручылар һәм катнашучылар әзерме?

Билгеле булганча, әлеге хәрәкәткә Татарстан 2016 елда кушылган иде. «Һөнәри компетенцияләрне үстерү үзәге» генераль директоры Эмиль Гобәйдуллин сүзләренчә, шушы вакыт аралыгында төбәк чемпионатларында 3 меңнән артык кеше катнашып өлгергән. «Абилимпикс» хәрәкәтенә бер мәртәбә кушылган кеше аның даими катнашучысына әйләнә. Бу исә – аларга һөнәри сәләтне, күнекмәләрне арттыру, аралашу даирәсен киңәйтү өчен дә яхшы мөмкинлек», – ди ул.

Быел «Абилимпикс» төбәк чемпионаты ярышлары 11 апрельдән 24 майга кадәр узачак. Осталыкны 87 юнәлештә сынаячаклар. Шулар арасында иҗат, сәнгать компетенцияләре, медицина, хезмәт күрсәтү, мәгълүмати технологияләр юнәлешләре дә бар. Ярышлар Казан, Түбән Кама, Арча, Чистай, Кукмара, Лениногорск, Бөгелмә, Нурлат, Чаллы, Әлмәт, Лаеш, Болгарда узачак. Быел 935 катнашучы (мәктәп укучылары, студентлар, белгечләр) көч сынашыр дип көтелә. Барлыгы 500 остаз, 400ләп волонтер җәлеп ителәчәк. Төбәк чемпионаты җиңүчеләрен август аенда Мәскәүдә көтәләр.

«Абилимпикс» кысасында эшлекле форум да оештырырга җыеналар. «Тигез мөмкинлекләр дөньясы» дигән форум 25 апрельдән 12 майга кадәр узачак. Форум кысасында семинар, остаханә, «түгәрәк өстәл»ләр оештыру күздә тотыла», – диде Эмиль Гобәйдуллин.

Катнашкан кешеләр белән ярыштан соң да элемтәне югалтмыйлар, кайсыларының ни белән мәшгуль булуын беләләр. Иң әһәмиятлесе – үзләренә эш табучылар саны арта. Эмиль Гобәйдуллин әйтүенчә, шулар рәтенә гомуми катнашучыларның 70 проценты карый. Кайсылары – үзмәшгуль, кайсылары өйрәнүләрен, күнекмәләрен арттыруны дәвам итә, эшли.

Илина Баймуратова Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать институтының 2 нче курсында укый. «Абилимпикс»ның «Фото» юнәлеше буенча җиңүчесе дә ул. Кызның күзләре начар күрә. Әмма бу аңа фотография сәнгате белән мавыгырга чик түгел.

– Беренче тапкыр «Абилимпикс»та 2018 елда катнаштым. Хәзер мин – илкүләм җыелманың киңәйтелгән составы вәкиле. «Абилимпикс»ның төбәк чемпионатларында ике мәртәбә җиңү яуладым. Ярышларга кадәр фотографиянең ни икәнен дә белми идем, фотоаппаратым да булмады. Остазларыма рәхмәт – алар минем ышанычымны арттырды. Мөмкинлекләре чикле кешеләр дә бик күп нәрсәне булдыра ала. Гаҗәпләндерер, бәлки: күзе күрмәгән кеше дә шәп фотограф була ала икән. «Абилимпикс»ка бер килеп әләккән кешенең аннан китәсе дә килми. Ул күңелдәге чикләрне атлап чыгарга ярдәм итә, – ди кыз.

БЕЛЕШМӘ ӨЧЕН

«Абилимпикс» хәрәкәте «Россия – мөмкинлекләр иле» Президент платформасына караган программа. Ул мөмкинлекләре чикле кешеләргә һөнәри осталыкларын күрсәтергә һәм арттырырга, социальләшергә, эшкә урнашырга мөмкинлек бирә. Хәрәкәт кысасында ярышлар 2015 елдан бирле үткәрелә. «Абилимпикс»ның Россиядәге эшчәнлеге кысасында барлыгы 414 төбәк чемпионаты оештырылган, ярышларда Россиянең 85 төбәгеннән 39632 кеше катнашкан.

ОЧСЫЗ-КЫРЫЙСЫЗ КҮК БИТ УЛ...

12 апрель – Космонавтика көне

Галимнәр бертуктаусыз тикшеренүләр алып барса да, космонавтларның саны айлап түгел, көнләп артып торса да, галәм кешелек дөньясын гаҗәпләндерүдән туктамый. Йолдызлы зәңгәр күк борын заманнан сәяхәтчеләр өчен компас ролен үтәгән. Бөек Тукаебыз да: «...күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул», – дип, юкка гына язмагандыр. Узган ел без беренче космонавт Юрий Гагаринның «Восток» корабленда җиһанга очуына 60 ел булуны билгеләп үттек. Быел исә Космонавтика көнен бәйрәм итә башлавыбызга 60 ел тулды.

Шул уңайдан «Җиһангирлар» инициатив төркеме җитәкчесе Хәлил ГАЙНЕТДИНОВ белән сөйләшеп алдык.

:: Хәлил Шәйхнурович, бер укучыбыз шалтыратты. Узган ел Космонавтика көненең 60 еллыгын бәйрәм иттек бит инде, быел тагын нинди бәйрәм соң ул, дип кызыксына...

– Юрий Гагаринның галәмгә очкан көне – безнең өчен олы бәйрәм. Халык исәп-хисапны 1961 елның 12 апреленнән алып барырга күнеккән. Шуңа күрәдер инде, Космонавтика көненең СССР Югары Совет Президиумы указы белән бер елдан соң гына гамәлгә куелганы күп кешегә мәгълүм дә түгел. Бу бәйрәмне кертү тәкъдиме белән илебездәге икенче очучы-космонавт Герман Титов КПСС Үзәк Комитетына хат яза. Әйтергә кирәк, 12 апрель ул хәзер инде Космонавтика көне генә түгел. 1969 елны Халыкара авиация федерациясе бу көнне Бөтендөнья авиация һәм космонавтика көне дип билгели. Ә 2011 елны Берләшкән Милләтләр Оешмасы инициативасы белән Кешенең космоска очкан көне дигән халыкара бәйрәм дип тә игълан ителде. Бу фактны рәсми төстә раслап, резолюциягә 60тан артык дәүләт вәкиле кул куйды.

:: 2016 елда Гагаринның галәмгә очуына 55 ел булу уңаеннан «Космос ул – без» дигән Гагарин дәресләре үткәрү гамәлгә керде. «Без космоска ышанабыз» дип аталган арт-проект ачылды. Аның сайтына космосны үзләштерү турындагы кызыклы вакыйгалар, фактлар куела. 2016 елда Россиянең 20 шәһәрендә «Башыңны күтәр!» флешмобы кысасында күккә Юрий Гагарин портреты төшерелгән 108 мең шар (беренче космонавт очышының һәр минутына 1000әр данә) очырылган иде. Мәскәүдәге Космонавтика музее, мәсәлән, #НеВыходиИзКосмоса проектын башлап җибәрде. Аның буенча виртуаль күргәзмәләр ачыла, архив документлары күрсәтелә. Кыскасы, ел саен нинди дә булса яңалык кертелә һәм ул традиция булып дәвам итә. Быел Космонавтика көнен ничек бәйрәм итәбез?

– Ил күләмендә алганда, барлык төбәкләрдә бәйрәм чаралары үткәрелә дип ышанам. Гадәттә төрле күргәзмәләр, экскурсияләр, фестивальләр, концертлар, спорт ярышлары зур колач ала. Мәктәпләрдә Гагарин көненә багышлап, тематик сәгатьләр үтә. Һәр төбәк үзенең мөмкинлекләреннән чыгып эш итә дип уйлыйм.

:: Татарстан ниләр белән сөендерә?

– Шактый эшләр эшләнә. Иң яңалары дигәндә, быел Россиядә беренче тапкыр буларак, Арчада Гагарин авыл хуҗалыгы ярминкәсе уздырыла. Монда башка авыл хуҗалыгы продуктлары белән төп товар орлыклык бәрәңге булачак. «Ни өчен?» дигән сорауга җавапны күпләребез беләдер дә инде. Бу хакта газетада язылган иде. Юрий Гагарин космостан Саратов өлкәсендәге Смеловка авылына төшкән. Аны беренчеләрдән булып татар хатыны Әнихәят апа оныгы Румия белән күреп алган. Алар кырда бәрәңге утырта торган булганнар. Шушы вакыйганы истә тотып, Әнихәят апа, һава торышының нинди булуына карамастан, 12 апрель көнне ел саен бер-ике данә булса да бәрәңге төртеп кергән. Бу традиция Румияләр гаиләсендә дәвам итә. Без дә аны сакларга тәкъдим итәбез. Гагарин ярминкәсендә һәр кеше бәрәңге утыртырга кирәклеген исенә төшереп, орлыклык әзерләп куйсын иде. Бу гамәл, традициягә әйләнеп, бөтен Россия төбәкләренә таралыр дип уйлыйм. Бүгенге вазгыятьтә бу бигрәк тә кирәк.

11 апрель көнне Арчадагы Казан арты музеенда Космонавтика көне – Гагарин көненең 60 еллыгына багышланган экспозиция ачтык. Экспонатлар арасында космонавтлар Валентина Терешкова, Сергей Рыжиков, космонавтика тармагында бүген эшләгән белгечләр, ветераннар биргән бүләкләр, тарихи документлар, фото-видео материаллар бар.

Ел саен уздыра торган чараларыбыз да дәвам итә. Безнең төркем тарихны да, яңалыкларны да халыкка җиткерү йөзеннән массакүләм мәгълүмат чаралары белән тыгыз эшли. «Ватаным Татарстан»ның Татарстаннан бердәнбер космонавт Сергей Рыжиков белән әңгәмә үткәрергә җыенганын беләм. Әле ул беренче тапкыр галәмгә очкач та, Арчада безнең төркем, җитәкчеләр белән киңәшләшеп, Җиһангирлар аллеясы булдырды һәм анда стела – Рыжиков очкан «Союз – МС 02» ракетасы куелды.

Физик яктан көчле булсаң гына, галәмне яуларга мөмкин. Димәк, бу көнне спорт ярышларының зур колач алуы да гаҗәп түгел.

Юрий Гагарин остазы Сергей Королев белән.

:: Хәтерлисездер, без балачакта космонавтларның исемнәрен хәтта яттан өйрәнә идек. Хәзер мәктәпләрдә бу бәйрәмгә игътибар ни дәрәҗәдә?

– Бу – бик җитди мәсьәлә. Мәгариф министрлыгы белән бергәләп эшләргә тырышабыз. Республика мәктәпләрендә, балалар бакчаларында ел саен 12 апрель көнне «Юрий Гагарин белән 108 минут бергә!» дигән чара үткәреп килдек. Шуңа өстәп, төрле рәсем, җыр, шигырь бәйгеләре үткәрелә. Космос темасына җырлар, шигырьләр бик күп, әмма аларны кайтарырга кирәк. Яңалары да булыр дип өметләнәбез. Монда балалар гына түгел, өлкәннәр турында да сүз бара.

:: Мондый тантаналарда бәйрәм табыны да үзенчәлекле булырга тиештер кебек.

– Гагарин бәлеше – менә дигән сый. Бу – уйлап чыгарылган әйбер түгел. Беренче космонавт татар ризыкларын бик яратып ашый. Бәлешне аңа хатынының Оренбургта яшәүче, пешекче-ресторатор булып эшләүче әтисе әзерли торган була. Без үзебез дә ел саен зур бәлеш салып, аны космик тематикадагы рәсемнәр – ай, йолдызлар, ракеталар белән бизибез. Мондый тәмле ризык янына Гагарин чәе дә бар. Тарихы мондыйрак. Беренче космонавт, галәмнән төшкәч, күп илләргә, шул исәптән Бөекбританиягә дә чакыру ала. Аны Елизавета II кабул итә. Очрашуга әзерләнгән өстәлдә лимонлы чәй була. Юрий Алексеевич чәйне эчә дә лимонны ашап куя. Мондый гадәт булмаганга, барысы да нык гаҗәпләнә, уңайсыз тынлык барлыкка килә. Елизавета II бу мизгелне үзенчә «йомшарта»: чәеннән лимонны ала да ашап куя. Аның артыннан барысы да шуны кабатлый.

:: Бу бәйрәмдә шулай да һәр татарның күңелен тырнап торган бер әйбер бар кебек. «Татарлар ник галәмгә очмыйлар икән?» дигән сорау милләттәшләребезне бик борчый.

– Беренче Гагарин отрядындагы 20 кеше арасыннан 12се генә галәмгә оча ала. Алар арасында милләттәшебез Марс Рәфыйков та була. Әмма төрле сәбәпләр белән аңа җиһанга күтәрелергә насыйп булмый. Соңрак тормышы бөтенләй башка юнәлеш ала. Әфганстан сугышында да катнаша. Шундый бер кызыклы тарихи факт та бар. Отрядтагы барлык кандидатлар «Беренче кем очарга тиеш?» дигән сорауга җавап бирү йөзеннән яшерен тавыш бирәләр. Анда Рәфыйков яклы бары берәү генә була. Соңыннан бу тавыш бирүченең үзе икәнлеге ачыклана. «Ник үзеңне сайладың?» – дип сорагач, «Мин – монда күк җиселе исемен йөрткән бердәнбер кеше, димәк, мин очарга тиеш», – дип җавап бирә. Гомумән алганда, без белгәне, заманында 11 татар космоска очарга әзерләнгән, барысы да төрле сәбәпләр белән төшеп калган. Арада Рафаэль Закиров игътибарга лаек. Ул ракеталар буенча бик шәп белгеч була, Кариб кризисы башлангач, аны космонавтлар отрядыннан алып, Кубага җибәрәләр. Урал Закиров бүген Казанда яши, физика-математика фәннәре докторы. Космос аппаратлары белгече буларак, Сергей Королев һәм Мстислав Келдыш кулы астында эшли. Космонавтлар отрядына керергә рөхсәт сорый. Кызганыч, медицина комиссиясен уза алмый. Тагын Чиләбе өлкәсеннән Саттаров Наил «Буран» программасы буенча очарга әзерләнә. Аның белән бергә Башкортстаннан татар егете Урал Солтанов та була. Тик, үзгәреш җилләре башланып, «Буран» проекты буенча берәү дә оча алмый. Әйе, бүген татарлар арасында космонавтлар юк. Бер яктан, кызганыч та кебек. Икенче яктан караганда, яшьләр, мәктәп балалары өчен татарның беренче космонавты булырга менә дигән форсат бит бу!

Әңгәмәдәш –
Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

«Татар-информ»

Шашкын мәхәббәт, гөнаһ һәм иман арасында бәргәләнү, фаҗигале язмышлар... Татар театры сәхнәсендә өр-яңа тема. Кәрим Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма театрында Илгиз Зәйниевнең «Мәдинә» спектакле премьерасы булды.

ТИНЧУРИН ТЕАТРЫНДА – ПРЕМЬЕРА

МӘДИНӘНЕҢ ТАРИХЫ НӘРСӘГӘ ӨЙРӘТӘ?

«Мәдинә» драмасының драматургы һәм режиссеры – Илгиз Зәйниев. Спектакльнең жанры гыйбрәтле хәл дип куелган. Рольләрне Резедә Сәлахова, Артем Пискунов, Альбина Гашигуллина, Салават Хәбибуллин, Ирек Хафизов һәм Гөлназ Нәүмәтова башкара. Премьераның бер үзенчәлеге – пьеса ак шигырь белән язылган.

– «Мәдинә» пьесасы нигезендә борынгы грек мифы «Медея» сюжеты ята. «Медея» сюжетының безнең җирлектә ничек була алганын уйладым. Мин шигырь язмыйм, ә бу әсәр ак шигырь белән язылган һәм ул үз урынын тапты, – ди моның турында Илгиз Зәйниев.

– Татар театры, татар сәхнәсе өчен, әлбәттә, бу – чит тема. Пьесаны беренче тапкыр укып чыккач, башта каршы килгән идем. Татар театры, тамашачысы өчен кирәк әсәрме, дип уйландым. Илгиз Газинурович ышандыра белде, «Тамашачы күрсен, белсен, бу бит – безгә дә хас темалар», – диде. Монда үлчәүнең бер тәлинкәсендә – намус, иман, икенчесендә – гөнаһ, җәза дигән нәрсәләр. Геройлар кайсы юлны сайлавын һәр кеше үзенчә аңлар, бәлки борчыган сорауларына җавап та табар, – диде спектакльдә Мәдинә ролен башкаручы Резедә Сәлахова.

Спектакль тормышта булган хәл-вакыйгаларга нигезләнгән. Сюжеты да гап-гади. Мәдинә белән Җәүдәт бер-берсен яраталар, әмма егет байлыкка кызыгып, башка кызга өйләнә. Ләкин алар очрашып йөрүләрен туктатмыйлар, гөнаһ кылып яшәүләрен дәвам итәләр. Моны аңласа да, кайнар сөю хисләрендә янган Мәдинә үзенә каршы килә алмый. Ахыр чиктә геройлар сайлаган юл аларны фаҗигагә китерә.

– Мәхәббәт – мәңгелек тема, аның матур ягы, ямьсез ягы була. Ул нинди зур бәхет китерсә, шундый ук зур фаҗигаләр дә китерә. Чынлап та, гыйбрәтле хәл. Театр сәхнәсеннән тормышның начар яклары күрсәтелә, уйланырга азык бирелә, шуннан нинди гыйбрәт алырга икәнен тамашачы үзе хәл итәр, – ди Җәүдәт ролен башкаручы Артем Пискунов.

Әсәрдә шәхеснең эчке каршылыгы калку итеп куела. Кызганыч, кешенең караңгы ягы якты ягын җиңүгә ирешә. Тормышка үтеп кергән имансызлыкның чагылышы булган бозыклык, гөнаһ, зина кылу кебек күренешләр – әнә шуның нәтиҗәсе. Геройларның гөнаһлы тормыш алып барганын декорацияләрнең кызыл төстә генә булуы да күрсәтә. Чөнки кызыл төс ул – мәхәббәт, ут-ялкын төсе дә, кан төсе дә, фаҗига төсе дә.

Гаять киеренке хис-кичерешләр «учагы»нда янган Мәдинә җанына тынычлык эзли, сабырлык сорап, Аллага мөрәҗәгать итә. Намазга басып, гөнаһларын юмакчы була, әмма гөнаһ кылудан туктый алмый. Психологик киеренке халәттәге кыз чынбарлык белән хыял чигендә яши, ул ниндидер аңсызлык, саташулы хәлдә. Мәдинә генә түгел, Җәүдәтнең хатыны Галия (Гөлназ Нәүмәтова) дә шулай. Ире хыянәт иткәнне белеп яшәгән хатынның «мин – иремнең бердәнбер хатыны» дип әйтүе дә – шуңа ишарә. Мәдинәнең дус кызы Нәфисә (Альбина Гашигуллина) образы да аерым игътибарга лаек. Дәртләреннән шашкан Мәдинә һәм Җәүдәттән аермалы буларак, Нәфисә дөньяга ялкынлы хисләр белән түгел, салкын акыл аша карый. Үзе эчтән янса да, «әйбәт әсәр» килеп чыксын өчен дустын да, сөйгән егетен дә сынау алдына куеп, язмыш белән уйнаганнарын күзәтеп торырга әзер ул.

Биредә мәхәббәт шатлык, бәхет, рәхәтлек белән бергә кайгы-хәсрәт, хыянәт, намус газаплары да китерү фикере яңгырап кына калмый, бәлки соңгысы вакыйга-күренешләрдә өстенлек итә. Җәүдәт җәзасын бу дөньяда ук ала, юл һәлакәтендә янып үлә. Мәдинәнең йөрәгендә нәфрәт очкыны һәм үч алу теләге кабына. «Үч алырга бер җай чыкмый калмас, булыр! Моның өчен мин тәмугны айкап чыгам», – ди ул. Кечкенә чагында балаларын ашаган песине күргән Мәдинә, песи кебек, карынындагы балаларын юк итә. Тик моның белән ул Җәүдәтне дә, аның нәсел калдырырга хыялланган әтисен дә җәзаламый, ә үз-үзеннән үч ала.

Мәдинәнең тарихы тетрәндергеч. Тормыш-көнкүреш вакыйгаларына нигезләнгән пьеса социаль-иҗтимагый яңгыраш ала, аерым шәхесләр трагедиясе халык фаҗигасе булып үсә. Татар театрында кешелек җәмгыятендәге иң актуаль проблемаларның берсен калкытып кую һәм аның нинди куркыныч китерүен сурәтләү шуның белән әһәмиятле дә. Әмма күңелдә «Юлдан язган хатынга Мәдинә исемен бирү ни дәрәҗәдә аклана?» дигән сорау калды.

Ләйсән САФИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7066 данә
Гомуми тираж – 16091 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 251

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040
Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+